**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА, АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ**
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРУ, ӘЙЛӘНЕШЕ һӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ һӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ**
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

# ПРИКАЗ

25.07.2018 № 12-07/129

Казан ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел,№ 79-ФЗ Федераль закон, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. “Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында” 07.11.2017 ел, № 12-07/195 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу боерыкны Татарстан Республикасы

Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Ж.Й.Әхмәтханов**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 25.07.2018 ел, № 12-07/129 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында

НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу нигезләмәдә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, эш сроклары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керүгә конституцион хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 22 статьясы (алга таба – Федераль закон) нигезендә, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын

биләүгә конкурс турында” 01 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмә, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында” 31 март, 2018 ел, № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – карар) белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14 март, 2011 ел, № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре” 11 декабрь, 2015 ел, № УП-1192 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда үткәрелә.

Конкурс Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең (алга таба – гражданлык хезмәте) вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс, Федераль закон нигезендә конкурс үткәрүне таләп иткән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең (аның бурычларын башкаручы затның) (алга таба – җитәкче) карары нигезендә игълан ителә.

1.4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар

резервына кертүгә конкурс, ел саен үткәрелә торган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен белгечләргә ихтимал ихтыяҗын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервын бәяләү нәтиҗәләре буенча, кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге тарафыннан оештырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына кертүгә конкурс Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең конкурс комиссиясе тарафыннан бу Нигезләмәдә күздә тотылган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс үткәрелми:

- “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр” (киңәшчеләр) категорияләренең гражданлык хезмәте вазыйфаларының билгеләнгән вәкаләтләре срогына билгеләгәндә;
- вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;
- Федераль законның 28 статьясындагы 2 бүлегендә, 31 статьясының 1 бүлегендә һәм 60.1 статьясының 9 бүлегендә күздә тотылган очракларда, гражданлык хезмәткәрен башка гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;
- гражданлык хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданин) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

- вазыйфаи бурычларны үтәү Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле вазыйфаи бурычларны үтәүгә кагылышлы гражданлык хезмәтенең кайбер вазыйфаларына билгеләгәндә;
- җитәкче карары нигезендә, гражданлык хезмәтенең кечевазыйфалары төркеменә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

I.7. Конкурс түбәндәге максатларда уздырыла:

- Россия Федерациясе гражданнарының, сәләте һәм һөнәри әзерлеге нигезендә, дәүләти гражданлык хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керүгә Россия Федерациясе гражданнарының конституцион хокукын, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итү;
- федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килеп, конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә иң кулай булган кандидатларны сайлап алу;
- гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервын булдыру.

1.8. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

- конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәгәндә барлык кандидатларны бертигез шартлар белән тәэмин итү;
- кандидатларны һөнәри яктан әһәмиятле объектив критерийләр нигезендә бәяләү;
- конкурсларда катнашучылар арасыннан конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфалары (кадрлар резервына кертүгә) таләпләренә туры килүче затларны билгеләү.

## II. Конкурс комиссиясен булдыру һәм аның эш тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурслар үткәрү өчен җитәкче боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе оештырыла. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәргәндә, җитәкче боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе комиссия рәисеннән, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе югында аның хокуклары һәм вазыйфалары конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына күчә.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә (гаризалар кабул итә, делолар булдыра, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерә һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына җитәкче һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлегеннән, административ һәм суд практикасы бүлегеннән) һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрелә торган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур подразделениесеннән, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре һәм җитәкче запросы буенча гражданлык хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр – бәйсез экспертлар сыйфатында, экспертларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакрылыган башка оешмалар вәкилләре керә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Кагыйдә буларак, ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе карары нигезендә конкурс комиссиясе составы яңартыла.

2.5. Вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законы нигезләмәләреннән чыгып булдырыла

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр бәрелеше ихтималын булдырмаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү) кимендә ике кандидат дәгъва кылганда үткәрелә һәм утырышта әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашканда, узды, дип санала. Фәкать гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына конкурс комиссиясе утырышын уздыру рнхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә.

2.9. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар бертигез икән, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

2.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителгән карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары кул куя.

2.11. Кандидатлар конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгәндә Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе карары белән тиешле конкурс процедураларының видео- һәм (яки) аудиоязмасы яисә стенграммасы булдырыла.

2.12. Конкурсны, конкурс комиссиясе эшен турыдан-туры оештыру һәм конкурс үткәрүне тәэмин итүне Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге хәл итә.

## III. Конкурста катнашучылар

Конкурска 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белүче һәм дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь

инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче һәм бу Нигезләмәнең 3.8 пунктында күздә тотылган срокта бу Нигезләмәнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган Россия Федерациясе гражданнары кертелә.

Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәгәндә, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына Федераль законның 57 статьясындагы 1 бүлегенең 2 яки 3 статьясында яисә 59.1 статьясының 2 яки 3 пунктында күздә тотылган дисциплинар шелтәгә ия булган дәүләт хезмәткәре кертелми.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) кандидатларга карата таләпләр дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә түбәндәге документларны тапшыра:

– шәхсән гариза (бу Нигезләмәгә 1 кушымта);
– Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган формада тутырылган һәм имза салынган анкета, фотосурәт белән;
– паспорт яки аны алыштыручы документ күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә;
– кирәкле һөнәри белемгә, квалификациягә һәм эш стажына ия булуны раслаган документлар:
– нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмөт (хезмөт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш) һәм гражданинның хезмәт (хезмәт итү)

эшчәнлегеннән раслаган башка документлар;

– нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган гражданинның белеме һәм квлификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук, гражданинның теләгенә карап, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация бирелү яки квалификацияне күтәрүне раслаган документлар, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре;

– гражданинның гражданлык хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулардай авырудан интекмәве турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 14 декабрь, 2009 ел, № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у учет формасы);

– Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә күздә тотылган башка документлар.

3.6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәте вазыйфасы биләп, конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре җитәкче исеменә гариза тапшыра.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләп, конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе исеменә язылган гариза һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча тутырып, имзасы салынып, үзе гражданлык хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте раслаган анкета, фотосурәте белән, тапшыра.

3.7. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) ризалыгы белән үзен дәүләт сере һәм закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлардан файдалануга рөхсәтне рәсмиләштерү процедурасы уздырыла, гражданин (гражданлык хезмәткәре) дәгъва кыла торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматлардан файдалануга бәйле булганда.

Гражданинның җитәкче исеменә язып тапышырылган мәгълүматларының

дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә автоматлаштырылган төстә тикшерелә.

3.8. Бу Нигезләмәнең 3.5 һәм 3.6 пунктларында күрсәтелгән документлар “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 21 календарь көне эчендә гражданин (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәрү юлы белән яки, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, югарыда телгә алып үтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә тапшырыла.

Нигезле сәбәпсез документларны вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (гражданлык хезмәткәре) аларны кабул итеп алудан баш тартуга нигез булып тора.

Нигезле сәбәп белән документлар вакытында тапшырылмаганда, тулы күләмендә тапшырылмаганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырылганда, җитәкче аларны кабул итү срокларын кичектерүгә хокуклы.

## IV. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурс үткәрелгәндә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралар кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү критерийләре Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең дәүләт хезмәте вазыйфаларына куела торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийләре һәм сайлап алынган ысуллар, конкурс үткәрелә торган вазыйфалар төркеменә һәм категорияләренә бәйле рәвештә, үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлау үзләре үтәгән конкурс биремнәре һәм үткәрелгән конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә хәл ителә.

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.4.1. Беренче этапта Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коорупциягә каршы көрәш бүлеге оештыра:

– Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасында конкурс үткәрү турында мәгълүматлар әзерләп урнаштыру, әлеге мәгълүматлар түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш: гражданлык хезмәтенең (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) вакантлы вазыйфасы атамасы, бу вазыйфаны биләү өчен квалификаңия таләпләре, гражданлык хезмәтен үтү шартлары; Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертү) кандидатлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итү срогы, конкурс үткәрүнең күздә тотылган срогы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, бәяләү ысуллары турында мәгълүматлар, гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи регламенты нигезләмәләре (вазыйфаи бурычларын, хокукларын һәм вазыйфаи бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыгын кертеп), грнажданлык хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, федераль порталда урнаштырылган башлангыч тестка сылтама, башка мәгълүмати материаллар;
– кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;
– гражданинның (гражданлык хезмәткәре) квалификация таләпләренә туры килүе (һөнәри белеме дәрәҗәсе, дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәтенең башка төрләре) стажы яки белгечлеге буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

2. Тикшерү барышында федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулардай хәлләр билгеләнгәндә, җитәкче тарафыннан аңа конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында язмача хәбәр ителә. Гражданин конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган очракта аңа конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәр, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә

3. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) дәгъва кылучы зат бу карарга Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

4. Конкурсның беренче этабын тәгәлләү шарты булып Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләт хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүче кимендә ике кандидатның булуы тора (бу очракта кандидатларны алга таба сайлап алу мөмкинлеге тәэмин ителә).

Вазыйфага карата квалификация таләпләрен канәгатьләндерүче кандидатлар булмаганда яки бер генә кандидат булганда, конкурс, узмады, дип танылла. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатларның таләп ителгән санда булмавы сәбәпле, конкурсның, узмады, дип танылуы турында язмача хәбәр җибәрелә.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, җитәкче конкурсның икенче этабын үткәрү датасы (конкурста катнашу өчен документларны кабул итү тәгәлләнгән көннән соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт сере яки закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлардан файдалануга рөхсәт рәсмиләштерү очрагында конкурсның икенче этабын үткәрү срогын җитәкче билгели.

Кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге конкурсның икенча этабы башлануга кимендә 15 календарь көне кала Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына һәм “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтына аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеге турында мәгълүматлар урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләр җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган кандидатларга – югарыда телгә алып үтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр хәл ителә:

– кандидатлар турында мәгълүматларны “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы” (алга таба – Кадрларның бердәм мәгълүмат системасы) Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертү;

– конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү;

– конкурс комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү) конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү.

Конкурслар процедуралары барышында кандидатларны бәяләү өчен кимендт өч төрле бәяләү ысулы кулланыла. Кандидатларга тест үткәрү һәм алар белән индивидуаль әңгәмә коруны оештыру мәҗбүри ысуллар булып тора.

4.4.7. Конкурс үткәрелгәндә, конкурс комиссиясе кандидатларны белеме һәм квалификациясе, гражданлык хезмәте яки башка дәүләт хезмәте үтүе, башка хезмәт эшчәнлеген алып баруы турында тапшырылган документлары, шулай ук тест үткәрү һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән кандидатларны һөнәри һәм шәхсән бәяләү ысулларыннан файдаланып үткәрелгән башка конкурс процедуралары, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфалары) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тест

үткәрү, реферат язу, практик биремнәр үтәү, индивидуаль әңгәмә.

4.4.8. Кандидатлар тест сынауларын электрон рәвештә уза.Конкурс комиссиясе кандидатларның тест сынаулары өчен сораулар исемлеген әзерли. Дөрес булмаган җавапларның рөхсәт ителгән саны 25 проценттан артмаска тиеш.

Сораулар исемлеге белән һәркемгә танышу мөмкинлеге тудырылырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә, һәм ул конкурста катнашучыларның түбәндәге документлар һәм норматив-хокукый актларны ни дәрәҗәдә белүләрен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

- Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен;
- федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын;
- дәүләт хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын;
- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе турында нигезләмәне;
- гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасының вазыйфаи регламентын;
- структур подразделение эшчәнлеге юнәлеше буенча норматив-хокукый актларны.

Кандидатларга тест биремнәренә җаваплар әзерләү өчен бер үк төрле вакыт бирелә.

4.4.9. Реферат язу өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар хезмәтенең гражданлык хезмәте вазыйфалары) буенча вазыйфаи бурычларны һәм вәкаләтләрне үтәгә бәйле мәсьәләләрне куллану киңәш ителә.

Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү очрагында реферат темасы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурс үткәрелә торган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур подразделениесе җитәкчесе тарафыннан, ә кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелгән очракта – кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган

гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе тормышка ашырыла торган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур подразделениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

Кандидатлар бер үк темага реферат яза һәм аны әзерләү өчен аларга бер үк төрле вакыт бирелә. Реферат кулдан язылырга тиеш. Реферат күләме – кимендә 5 бит.

Конкурс комиссиясе йомгакларны бәяли, кирәк булганда – бирелгән тема буенча материалны бәян итүнең сыйфаты һәм тирәнлеген, теманың ни дәрәҗәдә тулы ачылуын, тәкъдимнәрнең нигезлелеген һәм тормышка ашырыла алу-алмавын бәяли. Реферат нигезләмәләренең яңалыгы һәм фәнни кыйммәте белән аерылып торуы игътибарга алына.

4.4.10. Кандидатларга бер үк төрле практик биремнәр һәм җавап әзерләү өчен бер үк төрле вакыт бирелә.

4.4.11. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) ия булган структур подразделение җитәкчесе үткәрелгән тест, рефератны һәм индивидуаль әңгәмәне бәяләү нәтиҗәләре буенча һәр кандидатка бәяләмә әзерли.

4.4.12. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү) дәгъва кылучы кандидатларга тест сынавы үткәрү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тест сынавы үткәрү методикасы нигезендә хәл ителә.

4.4.13. Конкурс процедуралары барышында бердәм тест сынавы үткәрү хәл ителә. Тест сынавын үткәрүне оештыру, заявкалар нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан хәл ителә.

Тест сынавы уздыруга заявка Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы бүлеге тарафыннан, конкурс комиссиясе үткәрүгә кимендә ике атна кала, булдырыла.

Тест сынавы үткәрү “Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест сынавын үткәрүне оештыру мәсьәләләре” 11 декабрь, 2015 ел, № УП-1192Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тест сынавы уздыру методикасына туры китереп хәл ителә.

4.4.14. Тест сынавы аша үткән кандидатлар белән индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан уздырыла.

Индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатларга булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге темасы буенча бирелгән сорауларга кандидатларның телдән җавап бирүләреннән гыйбарәт, җавап бирү барышында конкурс комиссиясе, гражданлык хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук бу Нигезләмәдә һәм дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе  һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып, кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяли.

Кандидат белән индивидуаль әңгәмә тәмамлангач, конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы Карар нигезендә расланган форма буенча тутырыла торган конкурс бюллетененә, кирәк булганда – куелган баллга кыскача аңлатма биреп, кандидатны бәяләү нәтиҗәсен кертә.

Бәяләү 10 баллы шкала буенча хәл ителә.

4.5. Кандидатның йомгаклау баллы индивидуаль әңгәмә, башка конкурс биремнәре нәтиҗәләре буенча кандидатка конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелгән баллар белән кандидатның тест сынавы йомгаклары буенча туплаган балларының уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре кандидатларның рейтингын төзи.

4.6. Конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның

йомгаклау нәтиҗәсе булып конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән конкурс комиссиясе карары тора.

Бу нигезләмәнең 2.10 пунктында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча тупланган балларын һәм алган урыннарын күрсәтеп, кандидатларның рейтингын үз эченә ала.

4.7. Конкурска йомгак ясауга һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) кандидат турында карар кабул итүгә нигезләр булып кандидатлар тупалган тавышлар саны, кандидатлар вазыйфага дәгъва кылган структур подразделение җитәкчесенең фикере тора.

4.8. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар хезмәтенең гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары үткәрү турында карар кабул итүгә яки башка конкурс үткәрү турында тәкъдим кертүгә хокуклы.

4.9. Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене билгеләү турында җитәкче боерыгы чыгарыла һәм җиңүче белән хезмәт контракты төзелә. Комиссия шулай ук гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәсә дә, һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары югары бәяләнгән затны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итүгә хокуклы.

Кандидатның ризалыгы белән, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы нинди төркемгә кергән булса, шул ук төркемдәге гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен, аны кадрлар резервына кертү турында җитәкче боерыгы чыгарыла.

Гражданлык хезмәткәрен (гражданинны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү җитәкче боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүматлар конкурс тәмамланганнан соң 7 көн эчендә язмача җибәрелә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен

документларын электрон рәвештә җибәргән кандидатларга – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имазаланган электрон документ рәвешендә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүматлар шушы ук сроката татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Интернет» мәгълүмат-телекомуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

4.11. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

4.12.Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) дәгъвачыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч көн эчендә язмача гариза буенча аларга кире кайтарылырга мөмкин. Моңа кадәр документлар Татарстан Републикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе архивында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел эчендә саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.13. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына барып кайту, торак наймы, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану чыгымнары һ.б.) кандидатлар тарафыннан үз средстволары хисабына хәл ителә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә

______________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________________

дән

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________________

(гариза тапшыру вакытына яшәү адресы; эш урыны

______________________________________________

вазыйфасы)

______________________________________________

______________________________________________

(мобиль телефоны, эл. почтасы)

## Гариза

Мине Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм : ________________________

______________________________________________________________________________

(вазыйфа һәм подразделение атамасы)

“Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел,№ 79-ФЗ Федераль закон, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 01 февраль, 2005 ел, № 112 Россия

Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмә, шул исәптән вакантлы вазыйфага куела торган квалификация таләпләре белән таныштым.

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында хәбәрне e-mail яки югарыда күрсәтелгән мобиль телефон номеры аша җибәрүгә каршы түгелмен.

Гаризага кушып тапшырам:

_______________________________________________________________________

(кушып тапшырыла торган документларны санап үтәргә)

«_» __________ 20_ ел _____________________________________________

(имза) (тулы имза)